**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_01_» ___03___ 2017 ел.** **№ _50__**

2017 елгы язгы ташу чорында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы халкын һәм территорияләрен яклау чаралары турында

Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм 2017 елның язгы ташу чорында халыкны, хуҗалык һәм торак объектларын, гидротехник корылмаларны, юлларны һәм күперләрне яклау максатларында карар бирәм:

1. Расларга: - 2017 елның язгы ташу чорында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы халкын һәм территорияләрен яклау чаралары планы, 1 нче кушымта нигезендә; - Азнакай муниципаль районында 2017 елгы язгы ташу вакытында буаларны имин ачкан һәм саклаган өчен җаваплы затлар исемлеге, 2 нче кушымта нигезендә; - Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре һәм авыл җирлекләре территориясендә 2017 елгы ташу вакытында хуҗалык эчендәге күперләрнең, күпер кичүләренең, юлларның һәм су үткәрү торбаларының сакланышы өчен җаваплы затлар исемлеге, 3 нче кушымта нигезендә.

2. Азнакай муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләре: - язгы ташуга каршы чаралар оештыруны тәэмин итәргә; - халыкны һәм территорияләрне язгы ташуның тискәре нәтиҗәләреннән саклау чараларын үткәрүне контрольдә тотарга.

3. Азнакай муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә: - 2017 елгы язгы ташуның тискәре нәтиҗәләрен кисәтү чараларын үтәүне тәэмин итәргә; - «Татарстан Республикасы буенча 11 ОФПС» ФДКУның 87 нче ПЧ-сына планны 2017 елның 21 мартына кадәр гамәлгә ашыру турында

белешмәләр тапшырырга; - язгы ташу вакытында аның торышы турында көн саен мәгълүмат бирүне оештырырга «Татарстан Республикасы буенча 11 ОФПС»ФДКУның 87 нче ПЧ-да язгы ташуны үткәрүгә әзерләнү һәм аңа каршы көрәш буенча күрелә торган чаралар.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов